ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**“Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында” Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 22 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы законнарын, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы кабул иткән башка актларны бастырып чыгару һәм аларның үз көченә керү тәртибе турында” 2003 елның 6 августындагы 27-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 8; 2011, № 6 (I өлеш); 2013, № 4 (I өлеш); 2014, № 7, № 12 (IV өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш), икенче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“Интеграцияләнгән тулы текстлы хокукый мәгълүмат банкына (хокукый мәгълүматның эталон белешмәләр банкына) кертелгән Татарстан Республикасы законнарының, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы актларының текстлары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Президиумы актларының “Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы”нда бастырып чыгарылган текстлары шулай ук рәсми була.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 29 апрель
№ 37-ТРЗ

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ